ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 3-11-18, факс: (84379) 3-11-18.

___________________№________________

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге  Савино авылында 2023 елның 14 октябрендәге гражданнар җыенының 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Савино авылында 2023 елның 14 октябрендәге гражданнар җыенының 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы? :

Савино авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, дигән сорау буенча 2024 елның 12 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 51 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар санының 27 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе»  позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 27 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде, тыелып калдылар - ___0 катнашучы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Савино авылында халык җыены булып узды, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип  танырга.

2.«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе  авыл җирлегенең Савино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 14 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы?

Савино авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Савино авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә
. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Д.В. Морозов